**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

**17.11.2023 ел** **№ 88**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 05 февралендәге 106 номерлы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2023 елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында», Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советының 27.02.2014 № 106 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 9 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Бохарай авыл җирлеге**
**Совет рәисе** **Е.В. Груздева**